КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 декабрь г.Казань № 1679

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 26 август, 91 нче карары белән расланган 2023 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләменә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 26 август, 913 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 ноябрь, 1167 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2023 елга «Татарстан

Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләменә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 26 август, 913 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 25 декабрь, 1679 нчы
карары редакциясендә)

2023 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Табиб рецептлары буенча балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Балаларның яше | Бер елга эш башкару күләме, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән | 0 айдан 6 айга кадәр | 619 405 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 2 295 120 | 2 295 120 | 2 295 120 | 2 295 120 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 10 433 525 | 10 433 525 | 10 433 525 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | | | | | |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 21535»; | | | |

---